ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2025 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә өлеш кертү хакында хисап турында

«Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2025 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә өлеш кертү хакында хисапны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Казан (Идел буе) федераль университетының Татарстан Республикасын социаль-икътисадый һәм фәнни-технологик үстерүгә, стратегик технологик проектларны гамәлгә ашыруга зур өлеш кертүен, икътисад һәм социаль өлкә тармаклары өчен кадрлар әзерләүдә, аларны яңадан әзерләүдә һәм аларның квалификациясен арттыруда әйдәп баручы булуын, галимнәргә һәм студентлар стартапларына ярдәм итүдә активлыгын, республиканың сәламәтлек саклау һәм гомуми белем бирү системасын үстерүдә катнашуын билгеләп үтә.

Югарыда бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы <u>КАРАР БИРӘ:</u>

1. «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2025 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә өлеш кертү хакында хисапны хупларга.

2. «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенә «Өстенлек-2030» стратегик

академик лидерлык программасы кысаларында үсеш программасын гамәлгә ашыру эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Россия Федерациясе Фән һәм югары белем бирү министрлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2026 елның 19 феврале
№ 543-VII ДС